Сентябрь,2017

# Гимназия сулышы №1

25 нче гимназия укучылары газетасы

## Белем көне белән!





### Беренче кыңгырау!
### Беренче тапкыр,
### беренче сыйныфка!

Быел гимназия бусагасын 182 бала атлап керде.Алар өчен беренче тапкыр беренче кыңгырау яңгырады. 11 нче сыйныфның уку отличнигы- Емельянов Илья һәм 1нче В сыйныф укучысы Вәлиева Мәликә тантаналы линейкада беренче кыңгырау шалтыраттылар.



***Кадерле укучылар, укытучылар! Сезне яңа уку елы белән котлыйбыз. Сезгә зур уңышлар, сәламәтлек телибез. Укучыларга тырышлык, укытучыларга сабырлык юлдаш булсын!***





## *1 нче октябрь-Өлкәннәр көне*
## Үз эшенең остасы

Гимназиягә килеп керү белән сезне кем каршы ала ? Билгеле инде, Рәхилә апа. Ул инде унбиш ел буе гимназиянең алыштыргысыз вахта хезмәткәре, үз эшенең чын остасы.

Минем газета укучыларны аның белән якыннанрак таныштырып үтәсем килә. Идрисова Рәхилә Гыйният кызы Түбән Камада шәһәр төзелә башлаганнан бирле яши. “1964 нче елда килдем мин монда. Ул вакытта шәһәр дигәнең Төзүчеләр бистәсе иде. Эшчеләр баракларда яшиләр иде, “-дип сөйли Рәхилә апа. Озак еллар дәвамында шәһәр ашханәләрендә пешекче булып эшләгән Рәхилә апа. “Хезмәт ветераны”дигән мактаулы исеме бар. Тормыш иптәше Фаиз абый белән ике ул үстергәннәр алар. Уллары Рамил һәм Раил гаиләләре белән Түбән Камада яшиләр. Ә оныклары дүртәү Рәхилә апаның : ике кыз, ике малай. “ Оныгым Данил хәзерге вакытта Балтика флотында армия сафларында хезмәт итә. Әтисе Рамил дә үз вакытында Тын океан флотында диңгезче булып хезмәт итте,-”ди ул оныгы өчен чын күңелдән горурланып. Яше олы булуга карамастан, һәрвакыт хәрәкәттә Рәхилә апа. Вахта хезмәткәренең эше бик җаваплы. Ул гимназиянең сак, күзәтү, янгын системасының төзек , өзлексез эшләвен, турникетлар җайланмасының эшен күзәтә. Аның өстенә укучылар югалткан күп санлы пакетларны иясләренә тапшыру да аның эше. Эшен яратып, “бишлегә”башкара Рәхилә апа. Сүз уңаеннан Рәхилә апаны Өлкәннәр көне белән котлыйсым килә! Аның сәламәт, шат күңелле булуын, гимназиябездә озак еллар эшләвен телим!

Хуҗҗәтов Гадел, 7 нче Г сыйныфы

**Сезнең тормыш юлы матур тарих,**

**Күпләр өчен үрнәк булырлык.**

**Рәхмәт, дибез, сезгә чын йөрәктән,**

**Сезнең гомер — безнең горурлык.**



**«Агачларны саклыйк» акциясе**

Сентябрь аенда « Экология елы» кысаларында гимназия укучылары актив рәвештә макулатура тапшырдылар. Укучылар барлыгы 1,7 тонна макулатура җыйдылар. Ә менә 2нче Г сыйныфы укучылары барысын да уздырды, алар 340 килограмм макулатура тапшырдылар. Бу файдалы һәм кирәкле акция урманнардагы күпме агачны киселүдән саклап калды! Макулатура тапшыру эше уку елы барышында дәвам итәчәк.

Бакирова Алия, 6-нчы Д сыйныфы укучысы

## Укытучыларны һөнәри бәйрәмнәре белән котлыйбыз!

Минем яраткан укытучым.

Мин 6 нчы А сыйныфында укыйм. **Безнең** сыйныф җитәкчесе – Абдулвәлиева Халидә Фәиз кызы. Ул безгә рус телен һәм әдәбиятын укыта. Укытучыбыз үз фәнен бик ярата. Халидә Фәиз кызы дәресләрендә рус грамматикасының кыен кагыйдәләре безгә җиңел бирелә.

Без сыйныф белән дәрестән тыш чаралар да еш үткәрәбез. Чараларга әзерләнгәндә җитәкчебез безгә киңәшләрен әйтә, булыша.

**“Укытучы, Сезгә сабырлыклар**
**Бирелгәндер, ахры, Ходайдан.**
**Бәхет, уңыш Сезгә юлдаш булсын**
**Мактаулар барыр юлларда”**

Гыйльманова Алия, 6нчы А сыйныфы



**Укытучым үрнәгендә**

Илнур Мулланур улы Мәрданшин гимназиянең “Тормыш иминлеге нигезләре” укытучысы булып эшли. Ул дәресләрдә кеше тормышын куркыныч астына куя торган очраклар турында сөйли, алардан исән-имин котылу юлларын өйрәтә. Мин ТИН дәресен кәтеп алам,чөнки киләчәктә армиядә хезмәт итәргә уйлыйм. Укытучым – Илнур Мулланур улы кырыс армия хезмәтен үткән. Ул Алтай өлкәсендә танк гаскәрләрендә механик- йөртүче булган. Минемчә, яшь буынны тәрбияләүдә Илнур Мәрданшин кебек булдыклы, белемле ир-ат укытучылар бүгенге тормышта бик кирәк.

Гөбәев Булат, 7 нче Г сыйныфы укучысы

## Җәйнең күңелле мизгелләре

Ямьле җәй

Минем җәем бик кызык һәм күңелле узды. Ниһаять, быел июль аенда без әнием белән Испаниягә бару бәхетенә ирештек. Искиткеч матур Салоу шәһәрендә кунакханәдә яшәдек. Мине шәһәрнең гаҗәеп архитектуралы йортлары, тарихи биналары шаккатырды. Әнием белән аквапаркта булдык, Авентура портында ял иттек.” Феррари” машиналары паркында экскурсиядә булдык.

Август аенда мин Россия һәм Татарстан балаларының яраткан лагере Артекта булдым. Безнең уникенче отрядта төрле шәһәрләрдән килгән малайлар һәм кызлар ял итте. Әйдаманнарыбыз (вожатыйлар) безнең өчен күптөрле конкурслар ,флешмоб оештырдылар. Диңгездә рәхәтләнеп су коендык, кояшта кызындык. Ял вакыты беткәч яңа дуслар белән саубуллашу моңсу булды. Менә шундый мавыктыргыч икән ул Артек! Идрисова Азалия, 6нчы А сыйныфы укучысы





## Укучылар иҗаты

**Минем әбием һәм бабам .**

Минем әбием белән бабам Түбән Камада яшиләр. Әбием Кадрия хәзер лаеклы ялда. Ул яшь вакытта техникумда укыган. Аны тәмамлагач, шин заводына эшкә урнашкан. Озак еллар заводта эшләп пенсиягә чыккан әбием.Тырыш хезмәте өчен аны Мактау грамоталары белән бүләкләгәннәр.

Бабам Ренат гаҗәеп кеше . Ул өлкән яшьтә булса да, заводта электрик булып эшли. Җәйге айларны әбием белән бабам бакчада үткәрәләр. Аларның матур-матур чәчәкләргә күмелгән бакчаларында әтием-әнием белән мин дә ял итәргә барам. Мин бабам белән су сибәргә яратам. Шул вакытта әбием тәмле ризыклар пешерә.

Бабамның яраткан шөгыле бар. Ул шахмат уйнарга ярата. Ул мине дә шахмат уйнарга өйрәтте. Ял көннәрендә әбием, бабам янына барам. Алар шундый ярдәмчел, шәфкатьле кешеләр. Мин әбиемне , бабамны бик яратам. Алар безне- оныкларын сөендереп озак яшәсеннәр иде.





Әмир Фәйзуллин,

7нче В сыйныфы укучысы

**Табышмакларның җавабын тап:**

1. Бер тартмада бик күп дуслар
   Төрлесе төрле төстә.
   Ләкин алар барысы да
   Башкаралар бер үк эш.

2. Акчасыз керәсең ,
   Хәзинә алып чыгасың.

## Яраткан ел фасылым

**Табигать тын. Җәй моңайган.**

**Болыт шәленә төренеп, көз килә . (Г.Кутуй)**

Әйе, шагыйрь сүзләре белән әйтсәк , туган ягымда көз хакимлек итә. Мин көзге табигатьнең матурлыгына сокланып, урамда йөрергә яратам. Юл буенда үсеп утырган каеннар, юкәләр, өрәңгеләр хәзер күз явын алырлык алтын-сары төскә керделәр. Аяк астында коелган яфракларның кыштырдавы ишетелә. Мин яши торган урамда миләш агачлары үсә. Көзге миләштән матуррак агач юктыр, мөгаен. Әнә ул кып-кызыл җимешләре белән ут кебек янып тора.

Тротуар буйларында үскән үләннәр дә саф яшеллекләрен инде югалтканнар, көзнең кырыс кагыйдәләренә буйсынганнар.

Көзен һава торышы үзгәрүчән була.Бер көнне җылы булса, икенче көнне салкын булырга мөмкин. Яңгырлар еш ява. Кояшлы көннәр сирәк булганга, һава салкынча-дымлы. Көзге матурлыкка сокланып калырга ашыгыгыз, дусларым!

Фәйзуллин Айнур, 6 нчы В сыйныфы укучысы.

Котлыйбыз!

Гимназиянең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Дәүләтгәрәева Фәридә Наил кызын юбилее белән котлыйбыз. Сезгә сәламәтлекнең ныгын, бәхетнең олысын телибез. Авыр һәм мактаулы эшегездә Сезгә уңышлар юлдаш булсын !


- Баш мөхәррир: Хуҗҗәтов Гадел
  Фотограф: Габдуллина Карина
  Корреспондентлар: Гыйльманова Алия, Фәйзулин Әмир
  Проект җитәкчесе: Шарапова Нурия